РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«11» июнь 2026 ел Олы Кайбыч ав. № 49

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан башка түләүле эшне башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан башка түләүле эшне башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибе турында нигезләмәне расларга.

2. Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә Нигезләмә таләпләрен үз кул астындагы муниципаль хезмәткәрләргә җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башлыгы урынбасары Э.Х. Заһидуллинага йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының
2026 елның «11» июнь
49 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан башка түләүле эшне башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибе турында нигезләмә**

1. Әлеге Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре, контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрдән тыш (алга таба-муниципаль хезмәткәрләр) тарафыннан башка түләүле эшне башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибе турында нигезләмә (алга таба - Нигездәмә) Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә башка түләүле эшне башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә, хәбәрнамә рәвешен алдан хәбәр итү процедурасын, шулай ук хәбәрнамәләрне теркәү тәртибен билгели.

2. Әгәр бу мәнфәгатьләр конфликтына китермәсә һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда башкасы каралмаса, муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүче) алдан язма рәвештә башка түләүле эшне башкарырга хокуклы.

3. Башка түләүле эшне башкарырга ниятләгән муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) яллаучы (эш бирүче) вәкиленә аны үтәү башланганчы кимендә биш эш көне калганда башка түләүле эшне башкару турында хәбәр итәргә;

2) мәнфәгатьләр конфликтына китермәслек башка түләүле эшне генә башкарырга;

3) башка түләүле эш белән бары тик эш (хезмәт) вакытыннан тыш гына шөгыльләнергә;

4) башка түләүле эшне башкарганда «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясында каралган таләпләрне үтәргә.

Муниципаль хезмәткәр башка түләүле эш башкаруга бәйле рәвештә мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге турында шик булган очракта, муниципаль хезмәткәр мәсьәләнең асылы буенча карар кабул итү өчен мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә мөрәҗәгать итә.

4. Эш бирүче (яллаучы) вәкиленә башка түләүле эш башкару турында хәбәрнамә (алга таба - хәбәрнамә) муниципаль хезмәткәрләргә әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтагы форма нигезендә тапшырыла.

Хәбәрнамәдә башка түләүле эш турында түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) муниципаль хезмәткәр башкарырга тиешле эш турында белешмәләр (эш урыны, вазыйфасы, вазыйфаи бурычлары);

2) тиешле эшне башкара башлау датасы;

3) тиешле эш башкарылачак срок.

Югарыда санап үтелгән башка түләүле эш турында белешмәләр үзгәргән очракта, муниципаль хезмәткәр яллаучы (эш бирүче) вәкиленә кабат хәбәр итә.

5. Муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) хәбәрнамә тапшыра, ул ике эш көне дәвамында аны визалый.

6. Кергән көнендә хәбәрнамә әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган рәвеш буенча төзелгән башка түләүле эш турында хәбәрнамәләрне теркәү журналында теркәлә.

Теркәлү көнендә теркәлү турында тамга белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән хәбәрнамәнең күчермәсе муниципаль хезмәткәргә бирелә йә алу турында хәбәрнамә белән почта аша җибәрелә. Муниципаль хезмәткәргә тапшырылырга тиешле хәбәрнамәнең күчермәләренә, хәбәрнамәне теркәү датасы һәм номеры, әлеге хәбәрнамәне теркәгән затның фамилиясе, инициаллары һәм вазыйфасы күрсәтелеп, "хәбәрнамә теркәлгән" дигән язу куела.

7.Эшкә алучының (эш бирүченең) вәкиленә хәбәр ителгәннән соң, мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә теркәлә.

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан башка түләүле эшне башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибе турында нигезләмәгә 1нче кушымта**

____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________

(вазыйфа атамасы, инициаллар, яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) фамилиясе

____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________

(муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**Башка түләүле эш башкару турында хәбәрнамә**

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Сезгә (хезмәт вакытыннан тыш) башка түләүле эшне башкарырга җыенуым турында хәбәр итәм:

оешма исеме: ____________________________________________
____________________________________________;

Оешма адресы: ____________________________________________
____________________________________________;

Башкара торган вазыйфа: ____________________________________________
____________________________________________;

вазыйфаи бурычлар: ____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________;

Эш башкару срогы "____" ________ 20____ ел - "____" ________ 20____ ел

Күрсәтелгән эшне башкару мәнфәгатьләр конфликтына китермәячәк. Күрсәтелгән эшне башкарганда "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясында каралган таләпләрне үтәячәкмен.

(дата) ____________________ (имза)

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан башка түләүле эшне башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибе турында нигезләмәгә 2нче кушымта**

Башка түләүле эш башкару турында хәбәрнамәләрне теркәү
ЖУРНАЛы

| т/ б N | хәбәрнамәне теркәү датасы | хәбәрнамә тәкъдим иткән хезмәткәр вазыйфасы Ф.И.А. | Хәбәрнамә алган хезмәткәр Ф.И.А. | Хәбәрнамә алган хезмәткәр имзасы | хәбәрнамә биргән хезмәткәрнең хәбәрнамә күчермәсен алу турында имзасы | яллаучы вәкиленә хәбәрнамә бирү датасы | Хәбәрнамәне шәхси эшкә теркәү датасы | искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |